РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«03» _10_ 2025 ел №992

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы буенча
2025 елның IV кварталында гомуми
торак мәйданының 1 кв. м. уртача
базар бәясен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү" Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында"гы 03.10.2019 ел, № 888 карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «2024-2027 елларга Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проектын, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү" муниципаль программасын раслау турында"гы 28.05.2025 № 561 карары белән расланган, «2024 - 2027 елларга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Күрсәтелгән социаль түләүләр торак урыннар сатып алуга (төзүгә) федераль бюджет акчалары исәбеннән бирелә торган гражданнар категорияләре өчен социаль түләүләр күләмнәрен исәпләп чыгару өчен, 2025 елның IV кварталына Ютазы муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен (сумнарда) 53 571 (илле өч мең биш йөз җитмеш бер) сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05